**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге башкарма комитеты**
**КАРАРЫ**

2018 елның 30 ноябре                                                   82№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Иске Салман авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге уставы нигезендә 2018 елның 19 ноябрендәге 29 номерлы «Җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Иске Салман авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге гражданнарының кушымтада бирелә торган үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

ТР Әлки муниципаль районы
Иске Салман авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе:                                        Ф.И.Җәләлетдинов

Иске Салман авыл җирлеге
башкарма комитетының 2018
елның 30 ноябрендәге
82 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү киләсе календарь елның 1 гыйнварына кадәр җирле референдумда катнашуга һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә Иске Салман авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, 18 яшькә җитмәгәннәр, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 18 яшькә җиткән барлык гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына Иске Салман авылы, Иске Тахтала һәм Яңа Баллыкүл авылы мәгълүмат стендларында һәм Әлки муниципаль районы http://www.alkeevskiy.tatarstan.ru рәсми сайтының Иске Салман авыл җирлеге битендә басылып чыгу һәм халыкка игълан итү юлы, шулай ук кәгазьдә имзалатып тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллама белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Иске Салман авыл җирлеге башкарма комитетының шәхси счетына керә.

5. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмалары) башкаруга исәп-хисап ясау хокукына ия оешма аша яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы аша акча күчерү юлы белән башкарыла

6.Түләү фактын касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар раслый.

7. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Иске Салман авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018
елның 30
ноябрендәге 82
номерлы карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ______ №

Үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне
____________________бюджетына түләү турында
(муниципаль берәмлек исеме)

Түләүченең Ф.И.О. ______________________________
Адресы: ______________________________________
Нигезә: ______________________________________
Сезгә бер тапкыр түләнә торган түләүне ____________ вакыты
җиткәнче түләргә кирәк ______________________________
______________________________________ сум күләмендә
реквизитлар : __________________________________
Алучының банкы БИК ____________________________
Сч. № ______________________
Алучы Сч. № ______________________________
ИНН ______________________________
КПП ______________________________
КБК ______________ ОКАТО ______________
Түләү билгеләмәсе ______________________________
______________________________________________
______________________________________________

Җитәкче ___________________________
М.У. (имза) (имзаны җәелдерү)

**кисү линиясе**- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә № __________
Үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне
____________________________ бюджетына түләү турында
(муниципаль берәмлек исеме)
суммада _______________ сум.
Түләүче Ф.И.О. ______________________________
Адресы: ______________________________________
Алдым 20___ ел. "__" _______________ ______________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Киселгән өлеше хәбәрнамә тапшырылса, тутырыла һәм Иске Салман авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*